# Хәтерем эзләреннән

...Шәһәрдәге таш фатирдан мине
Эзләп тапты авылымның жаны.
Хәтергә бер күз салырга кушты,
Бушатты да тынны аз гына ул,
Элек әнкәй хат яздырган төсле,
Васыятен әйтеп яздыра ул...

*Харрас Аюп*

Хәтер... Кеше хәтере, нәсел-ыру хәтере, халык хәтере, тарихи хәтер... Хәтер үзенә бик күп нәрсәне сыйдыра — дөнья хәлләрен дә, аерым кеше тормышында булган вакыйгаларны да. Хәтер ул тарихны саклаучы да, аны юкка чыгаручы да була ала. Шулай да... «Тарихи Хәтер дигәнең гаҗәп тотрыклы, нык, хәтта үзенчә «ки-ребеткән» — үҗәт нәрсә икән, - дип язган иде 1994 елда, тарихи үзгәрешләр башланган чорда, академик М. Госманов «Гасырдан - гасырга» исемле җыентыкка кергән бер мәкаләсендә. — Күпме аны кырып, себереп ташларга теләсәң дә, һич тә юкка чыкмый. Бер җирдә бассаң, күмсәң, икенче урыннан тишеп, калкып чыгар ул. Калын асфальтны үтәли тишкән нечкә үлән сабагыдай төрле сәяси, идеологик тыюлар аркылы да киләчәккә таба уза ул Тарихи Хәтер. Йә көчсезләнеп кечерәйгән хәлдә, яисә, киресенчә, әллә нәрсәләр исәбенә үскән, зурайган рәвештә. Легендага, риваятькә әверелгән чынбарлык, тарихи фактлык дәрәҗәсенә дәгъва итә торган легенда, әкиятләр төсле...»

Хәтерем мине еракларга алып китә: мин балачагыма кайтам. Әле яңа гына Бөек Ватан сугышы тәмамланган еллар... Әби-бабайлардан ишеткән бәет-мөнәҗәтләр, китаплардан укыган әкият-риваятьләр, хикәя-легендалар сабый чагымнан ук мине тарихка алып кергән икән бит! Бу өлкәдә иң беренче сабаклар бирүчем исә «гади авыл карты» — Таҗи мулла абзый (Шакиров Таҗетдин — үсеп җиткәнче мин аның тулы исеме Таҗимулла дип уйлый идем) булган икән.

Авыл никадәр зур булса да, аның халкы, гадәттә, бер-берсен ишетеп, күреп, аралашып белә; ләкин бу белемнең чикләре дә бар. Шуңа күрә, күпмедер вакытка кадәр, мин Таҗимулла абзый белән таныш түгел идем. Аларның өе безнең өйдән шактый ерак, олы урамда урнашкан, Таҗимулла абзыйның төпчек кызы Сания дә миннән олырак. Сигез-тугыз яшемдә, нинди сәбәп булгандыр, хәтерләмим, мин Сания белән аларның өйләренә килдем. Аның этисе белән танышу минем өчен үзе үк гыйбрәтле булды: ул, зур кешене кабул иткән кебек, эшеннән аерылып, минем белән сөйләште, бер алма да тоттырды (1941-1942 елгы суыкларда алмагачлары корыган авыл өчен алма бик тансык нәрсә иде). Ләкин мине иң гаҗәпләндергәне: без килеп кергәндә, Таҗимулла абзый өстәл артында нәрсәдер укып-язып утыра иде! Саниядән дә сораштым, өйгә кайткач та төпченүемне дәвам иттем, ләкин күп нәрсә белә алмадым.

Мин бик үҗәт бала идем: башымда берәр сорау туса, җавабын тапмыйча, башкаларга тынычлык бирми идем. Таҗимулла абзыйның үзенә сораулар бирергә баштарак читенсенсәм дә, төрле сәбәпләр табып, аларга баргалый башладым, һәр килүемдә, хуҗалык эшләре белән мәшгуль булмаган вакытларында, аның кулында кәгазь-каләм күрә идем. Күршедәге бабайларның берсен

дә китап-кәгазь белән күрмәгән кызчыкка бу хәл бик гаҗәп, сәер тоелгандыр, күрәсең! Таҗимулла абзый, авылда зур хөрмәткә ия булса да, гади кеше — укытучы да түгел, кантурда да (колхоз конторасы һәм авыл советын без шулай атый идек) эшләми, ә һаман язу эшендә. Шуның белән бергә ул безнең эшләр белән дә кызыксына, мине сөйләштерә, кайчагында безгә авылыбыз турында төрле риваять-хикәяләр дә сөйләп ала. Аңа ияләшә төшкәч, мин дә үземне борчыган сорауны бирергә җөрьәт иттем, нәрсә язуын сорадым. Нәкъ шул вакытта мин аннан үземә таныш булмаган «*шәҗәрә*» сүзен ишеттем.

Шәҗәрәнең нәрсә икәнен Таҗимулла абзый безнең нәсел мисалында буыннар чылбырын әйтә-әйтә аңлатты: «Әтиеңнең исеме *Хаҗи* (Хаҗиәхмәт), аның әтисе *Мәхмүт* исемле булганын син беләсең. Ә әтиеңнең бабасының исемен беләсеңме?» Мин белмәвемне әйткәч, ул: «Мәхмүтнең әтисе *Ибраһим*, Ибраһимның әтисе *Бикташ,* Бикташның әтисе *Хуҗаш* исемле булган,- диде һәм өстәп куйды: — Менә бу сезнең нәсел чылбыры, ягъни шәҗәрә була». Кешеләргә җиде буын бабаларын белергә тиешлеген дә әйтте ул, үзенең авылда яшәүче нәселдәрнең шәҗәрәләрен торгызу белән шөгыльләнүен дә аңлатты. Исәннәрнең генә түгел, үлгәннәрнең дә исемнәрен белүнең мөһимлеген шул чагында аңлый башлаганмындыр кебек тоела миңа хәзер…